Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XLIII-8**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 26 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2006 елның 16 маендагы “Җир кишәрлекләре бирү нормалары турында” VII-5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга ярашлы итү максатларында, ТР ның 2018 елның 22 декабрендәге “Гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлар өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль закон кабул ителү уңаеннан Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 114-ЗРТ номерлы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2006 елның 16 маендагы “Җир кишәрлекләре бирү нормалары турында” VII-5 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 15.06.2007 № XVI-3, 04.04.2008 № XXVII-4, 03.11.2012 № XXI-4 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктындагы “,терлекчелек һәм дача төзелешенең” сүзләрен “һәм терлекчелекнең” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Вафин Ф.М.ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов